ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турындагы законнарны үтәү барышы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турындагы законнарны үтәү барышы хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдинов, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары И.Ә. Гыйниятуллин, «ЗООҮЗӘК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Р.Р. Нуруллин мәгълүматын тыңлап һәм шул хакта фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Соңгы вакытта Россия Федерациясе субъектларында, шул исәптән Татарстан Республикасында, этләрнең олыларга һәм балаларга ташлану очраклары ешаю җитди борчу тудыра, этләр кешеләрнең сәламәтлегенә зыян китерә һәм еш кына аларның һәлак булуына сәбәпче була. Хуҗасыз йорт хайваннары гына түгел, җәмәгать урыннарында, җирле үзидарә органнары тарафыннан махсус бүлеп бирелгән урыннардан читтә, хуҗалары тарафыннан муенчак һәм борынчак кидермичә йөртелә торган йорт хайваннары, шул исәптән сугышчан токымга карый торган этләр, потенциаль куркыныч тудыра.

2021 елда «Инцидент менеджмент» системасында һәм социаль челтәрләрдә хуҗасыз агрессив йорт хайваннарына карата гражданнардан 1447 шикаять теркәлгән, бу 2020 елга караганда 42 процентка күбрәк.

2021 елда хайваннар салган яралар буенча республиканың медицина оешмаларына 10221 кеше мөрәҗәгать иткән (мөрәҗәгать итү күрсәткече – 100 мең кешегә 275,45), бу 2020 елның шундый ук күрсәткечләреннән 3,25 процентка артык – 9960 очрак (мөрәҗәгать итү күрсәткече – 100 мең кешегә 266,78).

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хайваннар тешләве авыр йогышлы авыру – котыру чире барлыкка китерергә мөмкин.

2021 елда Татарстан Республикасында 16 муниципаль районда хайваннар арасында котыру чиренең лаборатор расланган 25 очрагы теркәлгән, бу 2020 елның шундый ук күрсәткеченә (18 муниципаль районда 37 очрак) караганда 32,4 процентка кимрәк.

Хайваннарга карата мөнәсәбәт мәсьәләләрен җайга салу зарурлыгына, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәттә билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр федераль дәрәҗәдә законнар белән җайга салынмауга бәйле рәвештә Татарстан Республикасында 2014 елның 7 мартында «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) кабул ителде.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт мәсьәләләре Россия Федерациясе субъектлары арасында беренчеләрдән булып Татарстанда җайга салынды.

2018 елның 27 декабрендә «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 498-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 498-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә керде. 498-ФЗ номерлы Федераль законның хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт өлкәсендәге эшчәнлекне җайга сала торган 16 һәм 18 статьялары нигезләмәләре 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керде.

Күп мәсьәләләрне җайга салу федераль дәрәҗәгә тапшырылуга бәйле рәвештә, 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип танылды һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, бу Законда шул исәптән әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре дә билгеләнде.

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә чаралар оештырганда Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирелде.

Хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү

максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «1000 кешегә хуҗасыз хайваннар саны нормативы турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 65 номерлы карар кабул ителде, анда Казан, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләре өчен тиешле нормативлар – 2,8 баш, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре өчен 2,0 баш итеп билгеләнде.

«2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2021 елда хуҗасыз хайваннар белән мөнәсәбәт өлкәсендә чаралар оештыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә 56 732,3 мең сум (2020 елда – 56 490,5 мең сум) акча бүлеп бирелде. Бүленгән субвенцияләр 2021 елда 10 769 хуҗасыз хайванны ауларга мөмкинлек бирде, бу 2020 елга караганда 1053 башка артык.

2022 елда хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә чаралар оештыруга субвенцияләр күләме 69 315,2 мең сумга кадәр арттырылды.

Тапшырылган вәкаләтләр кысаларында барлык муниципаль берәмлекләрдә дип әйтерлек хуҗасыз хайваннарны аулау эшләрен башкаруга махсуслаштырылган оешмалар белән шартнамәләр төзелде.

Шулай да, хокук куллану тәҗрибәсе күрсәткәнчә, хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә кайбер мәсьәләләр тулысынча җайга салынып бетмәгән, бу гражданнар арасында социаль киеренкелек тудыра.

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 2.5 статьясында билгеләнгәнчә, хайваннар (табигый ирекле хәлдәге кыргый хайваннардан, шул исәптән Россия Федерациясенең континенталь шельфы һәм бары тик икътисадый зонасы табигый ресурсларына карый торган хайваннардан тыш), йогышлы хайван авырулары таралуны булдырмау, шулай ук йогышлы хайван авырулары таякчыклары чыганакларын һәм таралу юлларын ачыклау максатларында, индивидуаль һәм төркемләп идентификация узарга һәм исәпкә куелырга тиеш. Күрсәтелгән норма 2015 елның 13 июленнән гамәлдә. Идентификация узарга һәм исәпкә куелырга тиешле хайваннар төрләре исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 22 апрелендәге 161 номерлы боерыгы белән расланды.

Ләкин бу нигезләмәләр, хайваннарны асрау, шулай ук идентификация уздыру һәм исәпкә кую буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафынан расланган ветеринар кагыйдәләр булмау сәбәпле, гамәлгә ашырылмый.

Моннан тыш, 498-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләнмәгән, бу исә законнарны үтәмәгән өчен җәзаның котылгысыз булуы принцибының төшеп калуына китерә.

Югарыда күрсәтелгән норматив хокукый актларның булмавы хайваннарның хуҗаларын ачыклау мөмкинлеген һәм аларга законнар

таләпләрен үтәү бурычын йөкләүне юкка чыгара. 498-ФЗ номерлы Федераль законда йорт хайваннарын асрау шартларын төгәлләштерә торган кагыйдәләрнең һәм бәяләү критерийларының булмавы (мәсәлән, «тиешенчә карау») хайваннар хуҗаларының үз хокукларыннан явыз нияттә файдалануына китерә.

Моннан тыш, 498-ФЗ номерлы Федераль законда «сәбәпсез агрессивлык» төшенчәсенең билгеләмәсе, шулай ук аны ачыклау критерийлары юк, бу хайваннарны сәбәпсез агрессивлык күрсәтә торган итеп тануны кыенлаштыра. Ауланган хуҗасыз хайваннарның күбесе шуның аркасында элеккеге яшәү урынына кире кайта.

Шулай итеп, хәзерге вакытта гамәлдә булган «аулау – стерильләштерү – вакцина ясау – кире кайтару» схемасы авыру хайваннар проблемасын хәл итәргә һәм аларның үрчүен бераз туктатырга мөмкинлек бирә, ләкин хайваннарның кешеләргә ташлануын бетерә алмый.

Күрсәтелгән проблемаларны чишү юлларының берсе – хуҗасыз йорт хайваннары өчен приютлар булдыру.

498-ФЗ номерлы Федераль законның 16 һәм 18 статьялары нигезендә хуҗасыз йорт хайваннары, аулап, хайваннар өчен приютларга тапшырылырга тиеш, бу приютлар дәүләтнеке, муниципаль яисә хосусый булырга мөмкин.

Хайваннар өчен приютларда хайваннарны карантинга ябу, вакцина ясау, стерильләштерү, маркировкалау чаралары уздырыла, шуннан соң алар йә элеккеге яшәү урынына (сәбәпсез агрессивлык билгеләре булмаганда), йә хуҗаларына кайтарыла (алар табылса), асрау өчен яңа хуҗаларга тапшырыла, юк итела (498-ФЗ номерлы Федераль законда каралган күрсәтмәләр булганда) яисә табигый рәвештә үлгәнче приютларда асрала.

Бүген Татарстан Республикасында хуҗасыз йорт хайваннарын тоту өчен приютлар төзү кирәклеге актуаль булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәгълүматы нигезендә хәзерге вакытта республикада 3 226 урынга исәпләнгән 19 приют (шуларның 2 се – муниципаль, 7 се – шәхси) эшли. Республиканың өч шәһәрендә (Әлмәт, Түбән Кама һәм Чаллы) киләчәктә 400 урынга кадәр киңәйтү мөмкинлеге булган, 250 урынга исәпләнгән хайваннар өчен приютлар төзү планлаштырыла.

Россия Федерациясе субъектларына федераль бюджеттан хайваннарга мәҗбүри стерлизация ясау буенча аеруча чыгымлы чараларны гамәлгә ашыруга финанс ярдәме күрсәтү шулай ук хайваннарның санын җайга салуның кискен социаль проблемасын хәл итү чараларының берсе була алыр иде.

Булган каршылыкларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хайваннарны мәҗбүри теркәүне, күпфатирлы йорттагы торак урында тотылучы йорт хайваннары саны нормативларын билгеләү, шулай ук җирле үзидарә органы карары белән хайваннар йөртү өчен

билгеләнгән урыннардан читтә борынчак һәм муенчак кидермичә этләр йөртүне булдырмау тәкъдим ителә торган «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты әзерләнде. Шулай ук күрсәтелгән закон проекты мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, балалар өчен уен мәйданчыклары территориясенә йорт хайваннарын кире кайтаруга (аулаганнан соң) чикләү билгеләүне тәкъдим иткән, ауланган хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен приютлар булмаган вакытлыча тоту урыннарында һәм пунктларында тоту мөмкинлеге билгеләгән.

2021 елның 11 июнендә күрсәтелгән закон проекты закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына (алга таба – Дәүләт Думасы) кертелде, ләкин 2022 елның 22 февралендә Дәүләт Думасы тарафыннан әлеге закон проектын кире кагу турында карар кабул ителде.

Шул ук вакытта билгеләп үтәргә кирәк, бүгенге көндә федераль дәрәҗәдә хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итү кирәклеге турында Дәүләт Думасына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советына (алга таба – Федерация Советы), Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Россия Федерациясе субъектларыннан күпсанлы мөрәҗәгатьләр килә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 498-ФЗ номерлы Федераль законга хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәттә гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Федерация Советына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате, 498-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү буенча Кемерово өлкәсе – Кузбасс Закон чыгару Собраниесе, Пермь крае Закон чыгару Собраниесе, Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесе закон чыгару инициативалары хупланды.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдинов, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары И.Ә. Гыйниятуллин, «ЗООҮЗӘК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Р.Р. Нуруллин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына Дәүләт Думасы

Советы карары (2022 елның 24 гыйнварындагы 18 номерлы беркетмә карарыннан өземтә) белән төзелгән Россия Федерациясе законнарына гражданнарны сукбай этләр һөҗүменнән саклауга юнәлдерелгән үзгәрешләр әзерләү буенча эшче төркем белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан тәкъдимнәр кертү һәм федераль законнарга тиешле үзгәрешләр әзерләгәндә күрсәтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алу өлешендә хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, узган календарь елы өчен ауланган хуҗасыз йорт хайваннарының уртача санын исәпкә алып, халыкның җан исәбенә туры килүче хайваннар нормативын ел саен яңадан карау мөмкинлеген карауны һәм кирәк булган очракта «1000 кешегә хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативы турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 65 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Профильле министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне, әлеге өлкәдә чараларның нәтиҗәлелеге максатчан күрсәткечләрен әзерләүне һәм аларны гамәлгә кертүне кертеп, оештыруны камилләштерүне, шул исәптән вакцинация һәм стерилизация ясалган хайваннар өлешен арттыруны тәэмин итүне.

4.2. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе белән берлектә Россия Федерациясе субъектларының, шулай ук Казан шәһәренең хуҗасыз йорт хайваннары санын билгеләү тәҗрибәсен өйрәнүне. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә хуҗасыз йорт хайваннары санын исәпкә алу системасын әзерләүне.

5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Җәмгыяттә хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт булдыруны, шул исәптән йорт хайваннарына ирекле стерилизация, вакцинация, маркировка ясауны кызыксындыру механизмнары булдыру юлы белән хуҗасыз йорт хайваннары белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатларында иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлекне тәэмин итүне.

5.2. Приютлар төзү, шулай ук йорт хайваннары йөртү өчен урыннар билгеләү эшен дәвам итүне.

5.3. Хуҗасыз йорт хайваннарының мәктәпләр, балалар бакчалары, хастаханәләр территориясенә һәм хайваннар керүнең из зур куркынычы булган башка территорияләргә керүен булдырмый торган чаралар кабул итү предметына социаль объектлар куркынычсызлыгына мониторинг үткәрүне.

5.4. Казан шәһәрендәге «ЗООҮЗӘК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгытенең хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт эшчәнлеген оештыру өлкәсендәге уңай тәҗрибәсен куллануны.

5.5. Халык белән хуҗасыз йорт хайваннарына ярдәм итү кирәклеге турында аңлату эшләре алып баруны, приютлардан хайваннар сайлап алу фикерен популярлаштыруны, хайваннар өчен приютларга волонтерлык ярдәме төрләре хакында мәгълүмат бирүне.

5.6. Муницираль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышларында хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында, шул исәптән хайваннар өчен приютлар төзү хакында мәсьәләне карауны.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгариф оешмаларында белем алучыларга, кинолог белгечләрен, экологларны һәм биологларны җәлеп итеп, агрессив хайваннар, шул исәптән этләр белән үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында мәгълүмат бирү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

7. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз йорт хайваннары белән вәзгыятьне яктырту эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

8. Дәүләт Думасында Татарстан Республикасыннан депутатларга түбәндәге федераль законнарның проектларын хуплауны тәкъдим итәргә:

– «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына хайваннар өчен приютларның килешүләр объектлары исемлегенә өстәмәләр кертү өлешендә үзгәреш кертү хакында» 68181-8 номерлы;

– «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү турында» (йорт хайваннарын тоту таләпләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү максатларында) 41446-8 номерлы.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 11 марты
№ 1357-VI ДС